Республика Татарстан

Глава Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы башлыгы

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

08.12.2022 Менделеевск ш. №43

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советында һәм Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 52 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советына һәм Башкарма комитетына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен камилләштерү максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башлыгының 2022 елның 24 июнендәге 17 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советында һәм Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 6 пунктындагы 5 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- әлеге Тәртипнең 7 п. нигезендә мөрәҗәгатькә җаваплар имзалау компетенциясенә керә торган районның җирле үзидарә Органнарының вазыйфаи затына килештерелгән җавап яисә хәбәрнамә җибәрә».

1.2. 7 нче пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Мөрәҗәгатькә җавапны район башлыгы, район башлыгы урынбасары, район башкарма комитеты җитәкчесе һәм аның урынбасарлары үз компетенцияләре нигезендә имзаларга вәкаләтле.».

2. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2022 елның 24 июненнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесенә йөкләргә

Район башлыгы Р.И.Беляев